ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 472 от «05» 12 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының 2022 елның
15 апрелендәге « Мамадыш муниципаль районы
«Мәгариф бүлеге» педагогик хезмәткәрләренең
һөнәри квалификация төркеменең белем бирү
эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник
тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен
гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Башкарма
комитеты «Мәгариф бүлеге» МКУнең
мәгълүмати-методик бүлеге хезмәткәрләре
хезмәте өчен түләү шартлары турындагы
нигезләмәне раслау хакында»115
нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2025 елның 05 ноябрендәге № № под-1761/25 боерыгы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясының икенче өлеше нигезендә, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итүнең тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 апрелендәге115 номерлы карары белән кабул ителгән Мамадыш муниципаль районы «Мәгариф бүлеге» педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты «Мәгариф бүлеге» МКУнең мәгълүмати-методик бүлеге хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 1 нче кушымтаның “Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре” бүлегенең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 1.13

0000015047

пунктны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

| | |
|---|---|
| «1.13. | «Профессиягә тугрылык өчен»күкрәк билгесе. |

2. 2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы А.М.Ефимов